**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«22» 05 2024 ел Яр Чаллы ш. №2278

Кече Шилнә авыл җирлегендә җирләрне җирле әһәмияттәге рекреацион билгеләнештәге махсус сакланылучы территорияләр җирләренә кертү һәм аларда махсус сакланылучы территорияләр булдыру турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә җирләрне җирле әһәмияттәге рекреацион билгеләнештәге махсус сакланылучы территорияләр җирләренә кертү, алардан файдалану һәм саклау тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Тукай муниципаль районы Советының 2020 елның 21 октябрендәге 2/11 номерлы карары, Тукай муниципаль районының җирдән файдалану һәм авыл җирлекләре төзелешен алып бару кагыйдәләре проектларын әзерләү буенча ведомствоара комиссиясенең 2024 елның 17 маендагы карары нигезендә

## КАРАР БИРӘ

1. Кадастр номеры 16:39:102105:450, мәйданы 925 кв. м, адресы (урнашу урыны тасвирламасы): Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Кече Шилнә авыл җирлеге, ял итү зонасы (массивы) (рекреация), з/у 102105/450; җирләр категориясе: сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшырулар, телевидение, информатика җирләре, космик эшчәнлекне тәэмин итү өчен җирләр, оборона, куркынычсызлык җирләре һәм башка махсус максатлы җирләр булган җир кишәрлеген Кече Шилнә авыл җирлегендә гражданнарның ялын, туризмын, физкультура-савыктыру һәм спорт эшчәнлеген оештыру өчен җирле әһәмияттәге махсус сакланучы территорияләр җирләренә кертергә.

2. Махсус саклана торган территория чикләрен кадастр номеры 16:39:102105:450 булган җир кишәрлегенең чикләренә туры килгән чикләрдә расларга.

3. Кече Шилнә авыл җирлегендә кушымта нигезендә җирле әһәмияттәге рекреацион билгеләнештәге махсус сакланылучы территория төзергә.

4. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 22.05 2278 номерлы карарына кушымта

